**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 593

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 август, 562 нче карары белән расланган Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 август, 562 нче карары белән расланган Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

егерме өченче абзацны төшереп калдырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә һәм дәүләт мөлкәтен карап тотуга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын хисаплап чыгару

тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 1 август, 563 нче карары.»;

12.1 һәм 12.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон формада учреждениегә бирелә. Учреждение җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаять югарыдагы органга (учреждениенең гамәлгә куючысына) бирелә.

12.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, учреждениенең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталыннан файдаланып, җибәрелә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\593.docx